**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.03.2021 г. Казань № 24од

Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территориясендә халык белән чара үткәрүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 497-ФЗ номерлы һәм «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 541-ФЗ номерлы федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 18 октбрендәге 01-02/125 номерлы боерыгы белән (2018 елның 5 июнендәге 50од номерлы, 2018 елның 21 сентябрендәге 105од номерлы, 2019 елның 13 сентябрендәге 120од номерлы, 2019 елның 11 декабрендәге 162од номерлы, 2020 елның 5 августындагы 75од номерлы, 2020 елның 2 октябрендәге 103од, 2020 елның 20 ноябрендәге 132од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территориясендә халык белән чара үткәрүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының
12.03.2021 № 24од
номерлы боерыгы
белән расланган

Татарстан Республикасының берничә муниципаль районы, шәһәр округлары территорияләрендә халык белән чараларны уздыруны килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

«Стандартка булган таләпләр эчтәлеге» графасында 2.5 пунктта:

6 пунктчада «медицина ярдәмен» сүзләреннән соң «һәм санитар хезмәт күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) паспорт яки Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклаучы башка документ (оештыручы физик зат булса);»;

түбәндәге эчтәлектәе $8^1$ пунктча өстәргә:

«$8^1$) анда катнашучылар саны 500 кешедән артып китә торган халык белән чараны оештыручының халык белән чараны оештыруга һәм үткәрүгә акча җыю өчен кулланыла торган банк счеты реквизитлары;»;

2.6 пунктта:

«Стандартка булган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында килеп чыга:
юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә).

Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алырга тиеш булган документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче бирә ала торган документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, яки дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 9 пункты»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр» графасында:

2.12 пунктта «дәүләт хезмәтләре» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр» сүзләрен өстәргә»;

2.13 пунктында «дәүләт хезмәтләре» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр» сүзләрен өстәргә»;

3 бүлектә:

3.1.1. пунктта:

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запрос җибәрү, белдерү кәгазен килештерү турында карар әзерләү һәм кабул итү яисә белдерү кәгазен килештерүдән баш тарту турында;

6 пунктчада «.» билгесен «;» билгесенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар өстәргә:

«7) гадәттән тыш хәл, террорчылык акты очрагында халык белән чара үткәрү урынын һәм вакытын үзгәртү;

8) халык белән чараны килештерүне бәяләү, хатлар һәм тәкъдимнәр.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запрос җибәрү, белдерү кәгазен килештерү турында яисә белдерү кәгазен килештерүдән баш тарту турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.4.1. Бүлек белгече:

халык белән чара үткәрү турында белдерү кәгазен карый;

халык белән чараны оештыручы булып юридик зат торса, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә электрон формада законнар белән билгеләнгән вакытка Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында запросны (алга таба - запрос) җибәрә;

әгәр халык белән чара мәдәни мирас объекты территориясендә үткәрелсә, мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына белдерү кәгазе җибәрә;

запроска җавап ала;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган җирлекләрнең булуын (булмавын) билгели;

гаризаны килештерү турында министр карары (алга таба – карар) проектын һәм гаризаны килештерү турында хат проектын (алга таба – килештерү турында хат) әзерли, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булганда, шулай ук Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетыннан халык белән чараны мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) территориясендә, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә уздыру мөмкин булмавы турында бәяләмә алган очракта – гаризаны килештерүдән баш тарту турында боерык һәм гаризаны килештерүдән баш тарту турында хат әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Кирәк булган очракта халык белән чара үткәрү урынын һәм (яки) вакытын үзгәртү турында аны үткәрү өчен халык белән чараны оештыручыга тәкъдим ителә торган конкрет урыннарны һәм (яки) вакытны күрсәтеп нигезле тәкъдимне үз эченә алган хат проектын әзерли (ә халык белән чараның төрле рәвешләрен үз эченә алган халык белән чараны үткәрү турында белдерү кәгазен алган очракта, оештыручы тарафыннан игълан ителә торган халык белән чараны үткәрүнең бер рәвешен сайлап алу турында), шулай ук халык белән чараны оештыручыга гаризада күрсәтелгән максатларның, формаларның һәм башка шартларның халык белән чараны уздыруның 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килми торган урыннарын бетерү турында тәкъдим (алга таба –хат-тәкъдим) әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Халык белән чара уздыру турында белдерү текстында булган мәгълүмат һәм башка мәгълүматлар халык белән планлаштырылган чараның максатлары һәм аны уздыру формалары Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә туры килми дип санарга җирлек калдырган һәм (яки) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында яки җинаять җаваплылыгы турындагы законнарда каралган тыюларны бозган очракта Бүлек белгече үз эченә халык белән чараны оештыручының яки чарада катнашучы башка кешеләрнең мондый җитешсезлекләр табылган очракта һәм (яки) мондый чараны уздыру барышында закон белән каралган тыюлар бозылган очракта билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылу мөмкинлеге турында мотивлаштырылган кисәтүне (алга таба – кисәтү) алган хат проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган мизгелдән ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты белән килештерү кирәк булган очракта - гариза башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган мизгелдән өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына юлланган карар проекты, килештерү турында хат, хат-тәкъдим, кисәтү проектлары.»;

түбәндәге эчтәлектәге 3.10 пункт өстәргә:

«3.10. Гадәттән тыш хәл, террорчылык акты очрагында гавами чара үткәрү урынын һәм вакытын үзгәртү.

3.10.1. Министрлыкка гадәттән тыш хәл, террорчылык акты турында мәгълүмат кергәндә яисә аларның барлыкка килүенең (кылынуының) алар нәтиҗәсендә халык белән чарада катнашучыларның куркынычсызлыгы тәэмин ителә алмый торган реаль куркынычы булганда, оештыручыга гавами чара үткәрү урынын һәм (яки) вакытын

үзгәртү турында тәкъдим җибәрелә.

3.10.2. Әгәр әлеге Регламентның 3.10.1 пунктында күрсәтелгән хәлләр халык белән чара уздырылган көнне яисә халык белән чара үткәрелгән көнне ачыкланса, халык белән чараны оештыручыга аны үткәрү датасын үзгәртү тәкъдиме белән, шулай ук кирәк булганда, халык белән чара үткәрү урынын һәм (яки) вакытын яңа хбелдерү бирү юлы белән үзгәртү тәкъдиме белән үткәрү мөмкинлеге турында хат җибәрелә.

3.10.3. 3.10.1 һәм 3.10.2 пунктларында каралган процедуралар әлеге Регламентның 3.4 – 3.5 пунктлары белән билгеләнгән тәртиптә, әлеге мәгълүмат кергән мизгелдән ике эш сәгате эчендә гамәлгә ашырыла.».

түбәндәге эчтәлектәге 3.11 пункт өстәргә:

«3.11. Халык белән чараны килештерүне бәяләү, хатлар һәм тәкъдимнәр.

3.11.1. Халык белән чараны килештерү (алга таба – килештерү) һәм хатлар-тәкъдимнәр түбәндәге очракларда кире алына:

вәкаләтле органнардан белдерү бирүче затның 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халык белән чараны оештыручы булырга хокукы булмау турында мәгълүмат керү;

халык белән чараны оештыручының халык белән чара үткәрү урынын һәм (яисә) вакытын Министрлык белән килештерү мизгеленнән алып һәм халык белән чараны халык алдында үткәрүгә кадәр халык белән чараның максатлары, рәвешләре һәм (яки) анда катнашучыларның игълан ителгән саны берьяклы тәртиптә үзгәрүе турында мәгълүмат таратуы (массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә яисә саны билгесез булган затлар даирәсенең мәгълүматны алу мөмкинлеген башкача тәэмин итү мөмкинлеге);

халык белән чараның максатлары, рәвешләре һәм (яки) анда катнашучыларның игълан ителгән саны берьяклы тәртиптә үзгәргән очракта, халык белән чара уздыруны оештыручы тарафыннан халык белән чара уздырылган көннән дә соңга калмыйча 54-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясында каралган тәртиптә халык белән чара үткәрү турында яңа хәбәр бирү бурычы үтәлми.

3.11.2. Әлеге Регламентның 3.11.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат алынганда Бүлек белгече:

килештерүне яки хат- тәкъдимне чакыртып алу өчен нигез булуны (булмауны) билгели;

нигез булган очракта халык белән чара үткәрүне килештерү турында күрсәтмә проектын үз көчен югалткан дип тану турында боерык проектын (алга таба – кире алу турында боерык) яисә хатны-тәкъдимне кре алу турында (алга таба – кире алу турында хат) әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта каралган процедуралар әлеге Регламентның 3.11.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат кергән мизгелдән бер эш сәгате эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен бүлек башлыгына юлланган бәяләмә турында күрсәтмә проектлары, бәяләмә турында хатлар.

3.11.3. Бүлек башлыгы чакыртып алу турында күрсәтмә, чакыртып алу турындагы хатлар проектларын тикшерә, аларны килештерә һәм министр урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта каралган процедура кире алу турында күрсәтмә проектлары, чакыртып алу турында хатлар килештерүгә кергән вакыттан алып бер эш сәгате

эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм министр урынбасарына килештерүгә җибәрелгән күрсәтмәләр проектлары, кире алу турында хатлар.

3.11.4. Министр урынбасары чакыртып алу турында күрсәтмә проектларын, чакыртып алу турындагы хатларны килештерә, аларны килештерә һәм министрга имзалауга җибәрә.

Әлеге пунктта каралган процедура килештерү өчен чакыртып алу турындагы күрсәтмә проектлары яки хатлар кергән вакыттан алып бер эш сәгате эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм министрга килештерүгә җибәрелгән кире алу турында боерык проектлары, кире алу турында хатлар.

3.11.5. Министр чакыртып алу турында боерык проектларына, чакыртып алу турында хатларга кул куя. Чакыртып алу турында кул куелган боерык, кире алу турында хат бүлеккә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, кул куюга чакыртып алу турында күрсәтмә проектлары яки хатны кире алу турындагы боерык проектлары кергән мизгелдән бер сәгать эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кире алу турында күрсәтмә, чакыртып алу турында министр кул куйган хат.

3.11.6. Бүлек белгече:

чакыртып алу турында боерыкка тәртип номеры бирә;

мөрәҗәгать итүчегә белдерү кәгазендә күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, халык белән чараны яисә хат-тәкъдимнәрне килештерүне кире алу турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта каралган процедуралар министр тарафыннан чакыртып алу турында боерыкка, кире алу турында хатка кул куйганнан соң эш сәгате эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә халык белән чараны килештерүне кире алу яки хатны һәм тәкъдимнәрне кире алу турында хәбәр итү.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында берничә муниципаль
район, шәһәр округы территориясендә
халык белән чараларны уздыруны
килештерү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта (тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
юстиция министры
Р.И.Заһидуллинга

______________________ (физик затлар өчен:
ФИӘ.и. (соңгысы – булганда),
адрес (почта һәм (яки) электрон),

телефон, кәрәзле телефонны да кертеп
_________________________________ юридик затлар өчен:
оешманың исеме, адрес (почта һәм (яки) электрон),
телефон, кәрәзле телефонны да кертеп

Халык белән чара уздыру турында белдерү

________________________________________________________________________

(оештыручының исеме)

Халык белән чара уздырылуы турында белдерә(м)
Халык белән чараның максаты ___________________________
Халык белән чараның формасы ___________________________
Халык белән чараны уздыру урыны (урыннары), катнашучыларның хәрәкәт маршрутлары, транспорт чараларын файдалану турындагы мәгълүмат

___________________________________________________________________________
Халык белән чараны уздыру көне, аның башлану һәм тәмамлану вакыты __________
Халык белән чараны оештыручының җәмәгать
тәртибен_________________________________________________
медицина ярдәмен_________________________________________________
санитар хезмәте күрсәтүне __________________________________________________
тәэмин итү формалары һәм алымнары.
Халык белән чараны уздырганда тавыш көчәйткеч техник чараларны куллану нияте

__________________________________________
Халык белән чараны оештыручының халык белән чараны оешыру өчен акча җыю өчен кулланыла торган счетының банк реквизитлары

___________________________________________________________________________

Халык белән чараны оештыручының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда) яки атамасы, аның яшәү яки тору урыны турында мәгълүматлар, телефон номеры

___________________________________________________________________
Халык белән чараны оештыручы тарафыннан халык белән чараны оештыру һәм уздыру буенча гамәлләр башкаруга вәкаләт бирелгән затларның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда)

_____________________________________________________

Документның әзерлеге турында белдерүегезне үтенәм

___________________________________________________________________________

(белдерү алымы)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, саклауга, анычклауга (яңартуга, үзгәрешләр кертүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхесне күрсәтмәүгә, блокировать итүгә, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә, шул исәптән автомат режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатыннан карарлар кабук ителүгә үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

_______________________________ ________________________________________

(гаризаны бирү көне)

(халык алдындагы чараны оештыручы һәм халык
алдындагы чараны оештыручы тарафыннан
аны оештыру һәм уздыру буенча гамәлләр
башкаруга вәкаләт бирелгән затларның имзалары)».